Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Күкшел авыл җирлеге Советы

КАРАР

2022 елның 25 октябре № 23

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге территориясендә Гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә Күкшел авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Күкшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 апрелендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге территориясендә Гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә (Күкшел авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 октябрендәге 2 номерлы, 2017 елның 29 сентябрендәге 22 номерлы, 2018 елның 17 сентябрендәге 24 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5.1.А пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.А. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләүдән түбәндәге категория затлар азат ителә:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин

ОГРН 1021607753298
ИНН 1623002022